ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЭБАЛАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧМУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯБАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.01.2023 Ябалак авылы № 12

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 7793,48 сум күләмендә билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитетының2022елның 31 гыйнварындагы ««Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 1 номерлыкарарын гамәлдән чыккан дип санарга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә https:// ebalak -kaybici.tatarstan.ru/веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең

рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ruвеб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзәтуллина М. Ф.

Ябалак авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 ел «30» гыйнвар
12 номерлы карарына
1нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек буенча хезмәтләр күрсәтүнең бәясе**

| **Хезмәтләратамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумга. )** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3343,60 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 895,12 |
| 4. Күмү (кабер казу һәмкүмү) | 3554,76 |
| Барлыгы | **7793,48** |

Ябалак авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 ел «30» гыйнвар
12 номерлы карарына
2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек буенча хезмәтләр күрсәтүнең бәясе**

| **Хезмәтләратамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумга. )** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | 420,34 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2923,26 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 895,12 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3554,76 |
| Барлыгы | 7793,48 |